РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Брюшлинского сельского поселения Менделеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге Советы

---

Р Е Ш Е Н И Е
2022 елның 9 декабреннән

К А Р А Р
№65

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмнәрен, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләр хезмәте өчен түләүне җайга салу һәм камилләштерү максатларында, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары депутаталарының, әгъзаларының, муниципаль берәмлекләр рәисләренең, рәисләренең, урынбасарларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары аудиторларының, һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары ни гезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлеге советы КАРАР КЫЛДЫ

1. Татарстан Республикасы Бөрешле авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 90 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән муниципаль берәмлек башлыгының айлык акчалата түләү күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга (2020 елның 27 ноябрендәге 13 номерлы )

2. Татарстан Республикасы Бөрешле авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы 90 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль берәмлек башлыгы, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары белән муниципаль хезмәткәрләрнең Бөрешле авыл җирлегендә билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга (2020 елның 27 ноябрендәге 13 номерлы )

3. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бөрешле авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 2 пункты нигезендә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 тапкырга арттырырга һәм аны 11958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatarstan.ru "Бөрешле авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Бөрешле авыл җирлеге Советы рәисе Л.А. Смирнова